Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Тайсуган авылы башкарма комитеты
КАРАРЫ

№ 5 «15» июль 2020 ел

Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен
анализлау тәртибен раслау турында

“Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2019 елның 16 декабренең 1230п номерлы күрсәтмәсен карап,

КАРАР БИРӘМ:

1. Гражданнарның кергән мерәҗәгатьләрен анализлау тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Тайсуган авылы, Сәләхетдинов урамы, 36б йорт; «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үземдә калдырам.

Әлмәт муниципаль районы
Тайсуган авылы башкарма
комитеты җитәкчесе М.Ф.Мостафин

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авылы башкарма комитетының 2020 елның «15» июль 5 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

Гражданнардан кергән мерәҗәгатьләрне анализлау
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы N 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авылы башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Тайсуган авылы башкарма комитеты кергән мерәҗәгатьләрне анализлау тиешле чорда килгән, шул исәптән: Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында теркәлгән "Электрон Хекүмәт" телефоны буенча язма рәвештә, Интернет-кабул итү бүлмәсенә яисә электрон почта аша, гражданнарны шәхсән кабул итү барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше системасында теркәлгән "кайнар линия" телефоны буенча кергән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

2. Гражданнарның мерәҗәгатьләренә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында җирле үзидарә органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясый.

3. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау елга 1 тапкыр башкарыла.

4. Кергән мерәҗәгатьләргә анализда кергән, яңадан каралган һәм каралган язма мерәҗәгатьләр, электрон документ формасында мерәҗәгатьләр саны, гражданнарны кабул итү урыннары, кеннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мерәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат булырга тиеш.

5. Гражданнарның мерәҗәгатьләренә анализ җирле үзидарә органнары тарафыннан Әлмәт муниципаль районының Тайсуган авыл җирлеге сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла.

6. Әлеге тәртипне бозуда гаепле вазыйфаи затлар кануннарда каралган җаваплылыкка тартылалар.

Әлмәт муниципаль районы
Тайсуган авылы башкарма
комитеты җитәкчесе М.Ф.Мостафин